| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.11.2025 Багай ав. №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Багай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 24 ноябрендә 10 сәгатькә Багай ав., Үзәк ур., 28 й. адресы буенча мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Багай торак пунктында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2025 елның 24 ноябрендә 13 сәг 30 минутка Багай ав., Мәктәп ур., 4 й. адресы буенча «Багай башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Багай торак пунктында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Багай торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясе тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, су ташу һәм халыкка су бирү системаларын төзү һәм ремонтлау;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (шул исәптән территорияне чабу);

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чар түгү урыннарын бетерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районының**
**Багай авыл җирлеге Башлыгы** **Р.Ф.Кузнецова**